| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлегенең Федотовка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең Федотовка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, көндезге бүлектә укучы студентлар, хәрби хезмә үтүче гражданнардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

- Федотовка авыл җирлеге Федотовка авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту;
- балалар мәйданчыгын җыю, урнаштыру, төзекләндерү;
- урамнарны яктырту;
--җирлекнең суүткәргеч милеген расланган исемлек нигезендә карап тоту, тапшырылган вәкаләтләргә туры китереп ремонтлау;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Федотовка авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 нчы йорт, Совет урамы, 8 нче йорт (мәдәният йорты бинасы),

Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 нчы йорт (СК бинасы) адреслары буенча халыкка хәбәр итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В.И.Павлова